Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XIV-4**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 15 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре Советлары тәкъдимнәрен кабул итәргә, әлеге авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарының түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында:

- авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирләрдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына кушымтаның үрнәк рәвеше нигезендә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын күздә тотып, Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 июлендәге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы органнарына тапшыру турында» XI-7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 15 декабрендәге
XIV-4 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ____________ авыл җирлеге органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

**КИЛЕШҮ**

Балык Бистәсе штп. «___»___________, 2016 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче, алга таба «район Башлыгы»дип аталачак ______________, бер яктан һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ________________авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ________________авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итүче, алга таба «җирлек башлыгы» дип аталачак _______________________, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

Әлеге килешүнең предметы булып район җирле үзидарә органнары тарафыннан җирлекнең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру тора:

- авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирләрдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, авыл җирлекләрен шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1.Районның җирле үзидарә органнары җирлекнең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне бирергә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары (алга таба - вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Районның җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләр үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны әлеге Килешүнең 4.1-4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә тикшереп торырга;

җирлекнең җирле үзидарә органнарыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны алырга.

2.3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән районның җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен, шулай ук Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүматны районның җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2.4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;
районның җирле үзидарә органнарыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә рәвештә файдаланырга.

## 3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бюджет законнары нигезендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме елына ____________________ сум күләмендә билгеләнә.

3.3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары максатчан файдаланмаган очракта, алар район җирле үзидарә органнары таләбе буенча ун көн эчендә район бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшереп тору

4.1. Районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, җирлекнең җирле үзидарә органнарыннан тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала. Җирлекнең җирле үзидарә органнары районның җирле үзидарә органнары соравы буенча соратып алынган мәгълүматны бирергә һәм аларның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керүен тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе районның җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Тапшырылган финанс чараларын тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан, шул исәптән районның җирле үзидарә органнары соравы буенча гамәлгә ашырыла.

## 5.Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.3. Якларның берсе дә аның өзелүе турында әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча белдермәсә, Килешү 2018 елга озайтылган дип санала.

## 6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

6.1. Әлеге Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

6.2. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә икенче Якка язмача рәвештә, аның гамәлдә булуы төгәлләнү датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлекнең җирле үзидарә органнары районның җирле үзидарә органнарына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кайтаралар.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як икенче Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3. Штраф түләү Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны алга таба үтәүдән азат итми.

## 8. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

8.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәс сөйләшүләр уздыру яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителмәгән очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән

рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү ике якның һәрберсе өчен берәр юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

**10. Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Балык Бистәсе муниципаль районы<br>Башлыгы<br>______________ ____________ | Татарстан Республикасы<br>Балык Бистәсе муниципаль районы<br>_______авыл җирлеге башлыгы<br>_______________ ___________ |